ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» 2016 елның 17 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә «җитештерелә торган һәм (яисә) әйләнештә булган» сүзләрен «әйләнештә булган» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары**

Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы 29-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чаралар, шулай ук түбәндәге юллар белән тәэмин ителә:

1) Татарстан Республикасында «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат тамгасын һәм аны куллану тәртибен билгеләү юлы белән «Милли сәүдә маркасы» системасын гамәлгә кертү;

2) базарда Татарстан Республикасындагы оешмаларның яисә индивидуаль эшкуарларның азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы таләпләренә туры килә торган азык-төлек продуктлары, материаллары һәм алар өчен кулланыла торган әйберләре сатылуны яхшыртуга ярдәм итү;

3) азык-төлек продуктларының конкурентлыкка сәләтен үстерүгә һәм базарда органик азык-төлек продукциясе, чималы һәм азык-төлек сатылуны яхшыртуга булышу;

4) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары һәм (яисә) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша хәбәр итү;

5) азык-төлек продуктларының, материалларның һәм алар өчен кулланыла торган әйберләрнең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән башка чараларын күрү.»;

3) 8 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «аларны җитештерүгә һәм аларның әйләнешенә» сүзләрен «аларның әйләнешенә» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 25 июнь
№ 33-ТРЗ